ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 429-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 429-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1985-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 пунктта «2 өлешенең 15 пунктын,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 пунктта «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктны өстәргә:
«12) 2027 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 15 пунктын.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында «Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен билгеләнгән ташламалы салым ставкаларының гамәлдә булуын озайтуны күздә тота.

Татарстан Республикасы территориясендәге торак пунктларны догазификацияләү буенча чараларны гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына ярашлы рәвештә 2022 елның 1 гыйнварыннан яңадан файдалануга тапшырылган 1,2 МПага кадәр басымлы газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата оешмалар өчен закон проектында 2027 елның 1 гыйнварына кадәр исәпләнгән салым суммасының 4,55 проценты күләмендә салым түләү рәвешендә преференцияне озайту каралган. Әлеге чара газ бүлү оешмаларының салым йөкләнешен киметүгә һәм Татарстан Республикасында газлаштыруны алга таба үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләренә, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр оештырылган коммерцияле булмаган оешмаларга мөнәсәбәттә гражданнарны бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгы алып бару өчен гомуми файдаланудагы милеккә карата салым салудан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр азат итүне озайту күздә тотыла. Салым ташламасы социаль булып тора һәм бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән.

Сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен кулланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата оешмалар өчен, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, халыкның медицина ярдәме сыйфатыннан канәгатьлеген арттыру һәм халыкның физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче өлешен арттыру максатларында, исәпләнгән салым суммасының 4,55 проценты күләмендә салым түләү рәвешендә билгеләнгән преференцияләрне 2025 елның 1 гыйнварына кадәр озайту каралган.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының**
**5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Өч ел эчендә Татарстан Республикасы территориясендәге торак пунктларны догазификацияләү буенча чараларны гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына ярашлы рәвештә 2022 елның 1 гыйнварыннан яңадан файдалануга тапшырылган 1,2 МПага кадәр басымлы газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата салым преференцияләре суммасы 388,5 млн.сум күләмендә бәяләнә, шул исәптән 2024 елда – 95,6 млн.сум, 2025 елда – 129,4 млн.сум, 2026 елда – 163,5 млн.сум.

Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләренә һәм сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен кулланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата социаль өстенлекләр суммасы 211,7 млн.сум тирәсе бәяләнә.